Чыганак: **Бакый Урманче иҗатында Габдулла Тукай: альбом = Габдулла Тукай в творчестве Баки Урманче: альбом / төз. Ф. В. Әхмәтова-Урманче.- Казан: Татар. кит.нәшр., 2007.- 207 б., рәс. б.**

# *«Тукай әсәрләре үзәк урында»*

*(Тукайның йозьеллыгына карата Татарстан радиосында Бакый Урманче белән Рөстәм Мәһдиев әңгәмәсе)*

Милли сынлы сәнгатебез күгендә беренче йолдыз, үзеннән соң чын мәгънәсендә гүзәл вә нәфис иҗат үрнәкләре калдырган рәссам, график, сынчы Бакый Идрис улы Урманче хәтеремә гомергә уелып кереп калды.

...Татарстан радиосында эшләп йөргән чаклар. Бөек Тукайның йөзьеллык юбилее якынлаша. Исәннәрдән шагыйрьне якыннан белгән, аның белән аралашкан, күргән кешеләр бармак белән генә санарлык. Бакый ага шул җөмләдән иде. Тукайны читтән генә булса да күреп, гомере буе шагыйрьнең иҗатын, аның образын мәңгеләштерү белән шөгыльләнгән уникаль шәхес белән очрашып, истәлекләрен магнитлы тасмага яздырып алу бәхете нәкъ менә миңа насыйп булды. 1986 елның гыйнвар азакларында Бакый ага яшәгән Союзная 6 урамына юнәлдем. Өч катлы торак йортның беренче катында өч бүлмәле фатирда Бакый аганың остаханәсе, ә икенче каттагы фатирда — аның «апартаментлары», шунда ул гаиләсе белән яшәп ята иде. Танышып сөйләшә башлавыбыз булды, без аның белән күптәнге дуслардай гәпләшә идек инде. Бераздан Флора ханым, сүзебезгә кушылып, безне чәйгә чакырды.

1958—1990 елларда Б.Урманче яшәгән йорт. Мөхәммәдьяров ур., 29

Дом, где жил Б.Урманче в 1958—1990 годы. Улица Мухаммадьярова, 29



Бакый аганың гадилеге, зыялылыгы, эчкерсезлеге мине чын мәгънәсендә әсир итте. Миңа, үзенә оныкбулырдай егеткә, ул фәкать «дустым» дип, якын итеп эндәшә иде. Теленең байлыгы, искиткеч эрудициясе, тормышның төрле мәсьәләләренә объектив бәя бирүе мине таң калдырды. Гаҗәп тә түгел: яшьтән үк белемгә омтылган ул, үсмер чагында прогрессив җәдиди «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган, аннан соң Казан һәм Мәскәү югары сәнгать уку йортларында белем алып, ниһаять, үзе дә беркадәр сынлы сәнгатьне укытканлыгы мәгълүм иде миңа. Классик белемгә ия булу өстенә ул шәрекъ, аурупа телләрен камил дәрәҗәдә белә. Гомумән, сәнгатькә мөкиббән кеше буларак, әдәбият, музыка буенча да хәбәрдар иде. Аның рәсем, нәкышь, сынлы сәнгать белән шөгыльләнгәндә «тәнәфес» ясап шигырь язуы, скрипкада уйнавы билгеле. Моннан тыш халкыбызның онытылып бетә язган озын, моңлы җырларын югары сәнгать дәрәҗәсендә башкара иде.

Сүз уңаеннан, халкыбызның борынгы «Ончы Фәхри» җырын үз гомеремдә беренче тапкыр Бакый ага башкаруында ишеттем. Хәер, бу хакта заманында шагыйрь Зиннур Мансуров бик мәгънәле һәм тирән эчтәлекле бер радиотапшыру да әзерләгән иде. Рәхәтләнеп шуны кабат тыңласаң иде!

Ап-ак чәчле, таза бәдәнле олпат әңгәмәдәшем тугызынчы дистәне тутырып килсә дә, зәп-зәңгәр күзләре егетләрчә, яшьлек дәрте белән ялтырый. Олы тормыш юлында кырыслыклар, шәхес культы елларында золым-зәүрәт тә аны читләтеп үткән диярсең. Ак диңгездәге Соловки утравы концлагере, ирекккә чыккач, туган туфрагыннан аерылырга дучар ителгән, Идел-йорттан еракта, тәмам онытылыр дәрәҗәгә җитеп, озак еллар дәвамында Урта Азиядә яшәп иҗат итәргә мәҗбүр булган ул. Һәм, ниһаять, 60 нчы еллардагы «җепшеклек»нең йомшак җилләре исә башлагач, туган иленә кайтып, чын мәгънәсендә халык мәхәббәтен казанган, рәсми хакимият тарафыннан иркәләү татып, олы яшьтә булуына карамастан, тормыш дәртен, иҗат итүнең тәмен җуймаган.

Г.Тукай яшәгән «Болгар» *кунакханәсе. XX йөз* башы открыткасы

Гостиница «Булгар», где *жил Г.Тукай. Открытка* начала XX века




Хәер, Бакый ага белән әңгәмәнең язмасына мөрәҗәгать итик. Тапшыру Татарстан радиосы эфирында шул ук елның февралендә яңгырады. Язма, мөгаен, бүген дә радио фондларында саклана-дыр.

**Рөстәм Мәһдиев.** Тукай һәм аның кабатланмас әсәрләре Сезнең иҗатыгызда төп урыннарның берсен алып тора, дисәм, ялгышмам. Сәнгатьтә беренче адымнарыгыздан башлап бүгенге көнгә кадәр Тукай темасына турылыклы булып калуыгызның сәбәпләрен ничек аңлатыр идегез?

**Бакый Урманче.** Бөек шагыйрьнең исемен ишетүгә, мин, хыялымда берничә дистә елны чигереп, яшьлегемә кайткандай булам. Ни өчен шулай? *Чөнки шагыйрь дә, мин дә Казанга бер үк елда, бер* үк айда килгәнбез. Мәгълүм булганча, Тукай Уральскидан килгән, мин исә Буа якларыннан, Күл Черкене авылыннан. Әлбәттә, бу факт миңа берни дә йөкләми, әмма әлеге вакыйга хәтеремә кереп калган һәм күпмедер дәрәҗәдә символик көчкә ия. Казанга килгәндә миңа 10 яшь иде. Мин — 1897 елгы, Габдулла Тукай — 1886 елгы. Күрәсездер, яшь аермабыз да әллә ни зур түгел. Ул заманда шагыйрь халык арасында инде танылган, популярлык казанган була. Аның иҗаты, таланты чәчәк аткан вакыт бу. Казанда 1907 елда ул милли сәнгатебез турында «Килер вакыт — халкыбыз арасыннан Шүрәлене тасвирлый алырдай талантлы рәссамнар чыгар әле» дигән өмет белдерә.

**Р.М.** Шагыйрьнең бу сүзләрен Сез шәхсән үзегезгә мөрәҗәгать дип кабул иттегез һәм җиң сызганып шул максаттан эшкә керештегез...

**Б.У.** Монда бернинди мистика булмаска тиеш. Бу сүзләр минем йөрәгемә үтеп керде, шуңа да мин үземнең беренче эскизларымны Шүрәле образын *сурәтләүгә багышладым.*

Мәскәүдәге Шәрекъне өйрәнү институты миңа Тукай портретын ясарга заказ бирде. Нәкъ менә шул елларда мин Тукай темасын үзләштерүгә тотындым. Тора-бара Шүрәле образы, шагыйрь әсәрләрендәге образлар галереясы минем иҗатымда үзәк урынны алды. Һәм бу темаларга мин гомерем буе әйләнеп кайта-кайта мөрәҗәгать итеп киләм.

**Р.М.** Бакый ага, менә бүген дә сезнең остаханәгездәге мольбертта Тукай һәм Фатих Әмирханны сурәтләгән яңа эскиз. Бу картинага алынуыгызга нәрсә сәбәп булды?

**Б.У.** Әйе, бу минем яңа эшем. Ул реаль тормыштан алынган, чынбарлыкка нигезләнгән. Миңа бит үз күзләрем белән Тукайны да, Фатих Әмирханны да күрергә насыйп булды. Фатих ага белән дуслашырга да өлгердем. Тукай белән танышырга да, сөйләшергә дә мөмкин түгел иде, чөнки теләсә кемгә ачылып китмәве мәгълүм. Фатих Әмирхан бик тиз аралашучан. Шуңа да аны халыктан, бигрәк тә яшьләрдән башка күз алдына китерүе дә кыен. Ул вакытта Фатих ага белән Габдулла Тукай «Амур» *номерларында яшиләр.* Аңарчы шагыйрь «Болгар» кунакханәсендә торды. Бераздан алар икесе дә «Амур»га күченделәр. Чөнки әлеге бинада «Кояш» гәзите идарәсе урнашкан. Фатих ага бу басманың сәркатибе булып эшләде. Алар җан дуслар иде. Без, мәдрәсәдә белем алучы шәкертләр, атнакич саен шушы «Амур» номерларының чәйханәсендә чәй мәҗлесләре оештыра идек. Биредә хуш исле чәй янында бик тәмле пәрәмәчләр әзерлиләр. Аш-су осталары бик уңган кешеләр. Ул вакытта исерткеч эчемлекләрнең нәрсә икәнен дә белмибез, һәм бу хакта сүз дә булуы мөмкин түгел. Еш кына без Тукай, Әмирхан яши торган икенче катка күтәреләбез. *Фатих аганы даими очратырга мөмкин,* чөнки



Г.Тукай портреты. 1959. Гипс. 86×90×87
Б.Урманче музеенда саклана. Казан

Портрет Г.Тукая. 1959. Гипс. 86×90×87
Хранится в музее Б.Урманче. Казань

заманында ул үзе дә «Мөхәммәдия»не тәмамлаган, шәкертләр белән гәпләшергә бик ярата.

Инде профессиональ төстә сынлы сәнгать белән шөгыльләнә башлагач, табигый, Тукайга һәм аның даирәсенә игътибарны юнәлттем. 1929 елда мин Казаннан китәргә мәҗбүр булдым һәм бары тик 1959 елда гына Ташкенттан кайттым. Үзбәкстанда яшәгәндә үк Тукайның бюстын эшли башлаган идем. Ташкентта эшем күп булса да, Тукай темасыннан аерылмадым. Казанга кайтып, иҗат ителгән эшләремне туплап, күргәзмә ясарга исәпләдем. Шуңа да шагыйрьнең бюстын мәрмәрдән эшли башладым һәм Казанга алып кайттым. Бу эшкә бик зур әһәмият бирдем. Ташкентта аны эшләгәндә, Тукайны якыннан белгән кешеләр исән иде әле. Шулардан Шакир Мөхәммәдъяров — Тукайны Санкт-Петербургка озата барган кеше. Ул вакытта Шакир ага студент, Санкт-Петербургта укый. Тукай белән ул Казанда Учительская школада укыганда танышкан. Замандашларының истәлекләре буенча Шакир Мөхәммәдъяров шагыйрь даирәсенә мөнәсәбәте булган алдынгы карашлы прогрессив яшьләргә якын торган.

Без аның белән шагыйрьнең язмышы, иҗаты турында озаклап гәп кора идек. Бүгенгедәй хәтеремдә: бюст әзер булгач, Шакир ага шаккатып карап торды да:

— Тукай бит бу! Каяле, — дип, сынны кочып алды.

Чынлап та, бюст бик уңышлы чыкты. Сәнгать белгечләре дә аны бик югары бәяләделәр. Мин моңа, әлбәттә, бик шат идем.

**Р.М.** Бакый ага, иҗатыгызда бөек шагыйрь төп урынны алып тора. Моннан тыш сезнең хезмәтлә-

регез арасында шагыйрьнең замандашлары, Тукайга якын кешеләрнең дә портретлар галереясы бар, аның фикердәшләренә багышланган әсәрләрегез байтак...

**Б.У.** Шагыйрьгә иң якын кеше, әлбәттә, Фатих Әмирхан. Сәбәп — фикерләренең уртаклыгында гына түгел, ә бәлки Фатих аганың шагыйрь карашлары формалашуына зур йогынты ясавындадыр. Тукайга татар тарихы, мәдәнияте, мәгарифе турындагы алдынгы идеяләрне сеңдерүдә нәкъ менә Фатих Әмирханның йогынты ясавы мәгълүм. Ул гына да түгел, Ф.Әмирхан, минем уемча, XX йөз башында татар иҗтимагый фикере үсешенең үзәгендә торган шәхес. Ул бик төпле белем алган кеше: атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган һәм Казан университетына керергә әзерләнгән. Фатих абый гарәп, фарсы, төрки телләрне яхшы белүе өстенә берничә аурупа телен дә белгән, төрле өлкәдә белемле, тарих, сәясәт, икътисад, мәдәният мәсьәләләрендә хәбәрдарлыгы билгеле. Шунысын да әйтим, Фатих Әмирхан бөек шагыйрьнең дусты гына түгел, күпмедер дәрәҗәдә аның рухи остазы да иде. Мин шагыйрь Сәгыйть Сүнчәләй белән бик якыннан таныш идем. Без Казанда таныштык. Аның портретын иҗат итәргә җыенам.

Шагыйрьнең замандашларыннан Мәҗит Гафури, Шәехзадә Бабич, Нәкый Исәнбәт, Дәрдемәнд, Галимҗан Ибраһимов, Хөсәен Ямашевларның портретларын ясадым. Гафур Коләхмәтов портретын да ясыйсы бар. Аның образы минем хыялымда өлгереп җитте инде. Күренекле замандашларыбыз портретларын иҗат итәргә җыенам. Кемнәр соң алар? Иң элек — Фәрит Яруллин. Аның рәсеме тәгәлләнеп килә. «Шүрәле» балетының авторы була-

Г.Тукай белән дусты Ф.Әмирхан әңгәмәсе. 1987. Киндер, майлы буяу. 138×111

Г.Тукай в общении с другом Ф.Амирханом. 1987. Холст, масло. 138×111





Көфер почмагы. 1977. Кәгазь, тушь. 65×44

Угол неверных. 1977. Бумага, тушь. 65×44

рак, аның Тукай иҗатына мөнәсәбәте ап-ачык. Шуннан соң Нәҗип Җиһанов. Аның бюстын эшләп бетердем. Ул бит «Кырлай» симфониясен язган композитор. Шулай итеп, мин Тукайны яхшы белгән, аның иҗатына кагылышы булган шәхесләрне мәңгеләштерүне үземә бурыч итеп куйдым.

**Р.М.** Иҗатыгызның зур өлеше бөек шагыйрь әсәрләрендәге образларны тасвирлауга багышлана. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасындагы Печән базары образларын истә тотуым. Бу темаларга мөрәҗәгать итүегез очраклы түгелдер?

**Б.У.** Әйе, шагыйрьнең иҗаты мине һәрдаим кызыксындырып торды. Мәсәлән, Печән базары темасы буенча эскизларны күптән ясый башлаган идем. Минем хыялым Тукай күргәзмәсенең бер өлеше генә түгел, ә бәлки татар халкы өчен үзенә күрә мәдәни үзәк булдыру иде. Биредә халкыбызның көнкүреше, гадәти тормышы һәм мәдәнияте тупланды. Шушында ук дистәләгән нәшрият, гәзит һәм мәҗмуга идарәләре, кунакханәләр, ашханәләр урнашкан. Анда зыялылар, шагыйрьләр, язучылар, сәүдәгәрләрне күрергә мөмкин булган. Шулар арасында күпме тарихи шәхес, күпме күренекле зат! Бу хезмәтне мин иллюстрация итеп кенә түгел, ә бәлки Печән базарын Тукай күзләре белән күрергә теләдем. Бу темага шактый күләмле фриз башкарган идем. Казанның яңа музеенда аны зур мәйданда урнаштырырга исәбем бар[1]. Шушы ук темага берничә фрагмент эшләдем. Алар гомуми бер композициягә берләштерелгән[2]. Моннан тыш Печән базарының масштаблы эскизын эшләп бетердем[3]. Анда кайбер тарихи шәхесләрне күрсәтергә омтылдым. Минем үземә дә кызык иде. Мәсәлән, шул ук «Көфер почмагы»н гына алыйк. Анда иске карашлы, тәрәккыяткә каршы көрәшкән затлар җыйнала иде. «Ислам дине кануннары, традицияләр, әхлак сагында торабыз», — дип, алар яңалыкка каршы чыктылар. Мода буенча тегелгән костюм кигән егет яки чәчен ауропача ясаткан, йөзен капламыйча йөргән кызларны — һәркемне мыскыл итеп ләззәт алдылар. «Көфер почмагы»ның иң күренекле вәкиле — Мөхәммәтҗан хафиз. Бөек артист Габдулла Кариевның хафиз образын оста итеп уйнавы истә калган.

**Р.М.** Габдулла Тукай Печән базарындагы кешеләрне сатирик планда күрсәткән. Аларның наданлыгыннан, ахмаклыгыннан, булдыксызлыгыннан каһкаһәләп көлеп мыскыл иткән. «Кисекбаш» поэмасын, сатирик әсәрләрен искә төшерик...

**Б.У.** Тукай аларның кайбер тискәре сыйфатларын гротеск дәрәҗәсенә җиткереп фаш итә. Һәм алар минем күз алдыма әйтерсең лә тере килеш килеп басалар. Мәдрәсәгә барганда да, аннан кайтканда да мин көненә берничә тапкыр шул карт

---

[1] Бу әсәр остаханәдә калды. Тукай музеена башка эскизы куелды.
[2] Алар бу китапта дөнья күрә.
[3] «Печән базары» Б.Урманче музеена алынды.

янынннан үтеп китәм. Аның тирәсендә һәрвакыт искелек тарафдарлары җыелып гәп куертып торган булыр иде. Аларның игътибар үзәгенә эләгүчегә кызыкмассың. Ул кеше «Көфер почмагы»ннан ник үткәнен гомергә үкенеп искә алырлык була иде.

**Р.М.** Бакый ага, шушы арада бөек шагыйрьнең юбилеена багышлап ачылачак күргәзмәдә күңелегезгә иң якын кайсы әсәрләрегезне урнаштырырга булдыгыз?

**Б.У.** Күргәзмә комитетына язган тәкъдим хатымда музейларда булган бөтен нәкышь әсәрләремне һәм сыннарны туплап экспозициягә куюларын үтендем. Тукай иҗаты минем эшчәнлегем өчен әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия. Бөтен иҗатым бөек шагыйрь темаларына багышланды, дисәм дә ялгышмам. Тукай замандашларының скульптур портретларыннан торган тулы бер серияне иҗат иттем. Шуларга ук нәкышь һәм графика эшләрен дә кушсак, шактый саллы экспозиция тәшкил була. Алар барысы да минем үземдә һәм өлешчә төрле музейларда саклана. «Шүрәле» темасына гына да аклы-каралы вариантта дистәләгән сериям бар. Агачтан юнып эшләнгән кече формада скульптур әсәрләрем дә күргәзмәгә куелачак.

**Р.М.** Бакый Идрисович, шушы күргәзмәне уздыруның әһәмиятен сез ничек бәяләр идегез?

**Б.У.** Экспозицияне оештыру — безнең изге бурычыбыз. Чөнки Тукай — уникаль, кабатланмас шагыйрь һәм татар әдәбиятының иң күренекле вәкиле, бөек шәхес. Аның иҗаты мәгънәви яктан сәнгати формаларга бай. Шагыйрьнең кайсы гына әсәрен алма, андагы образларны сынлы сәнгать чаралары аша тасвирлап бирү иҗади якын килүне сорый. Һәм музыкада да шундый ук хәл. Әмма сынлы сәнгатьтә образны тасвирлап бирү аеруча кыен. Чөнки шагыйрьләр нигездә философлар бит. Алар фәлсәфи категорияләр ярдәмендә фикер йөртәләр, иҗат итәләр. Мисалга Дәрдемәнднең иҗатын гына алыйк. Аның әсәрләренә иллюстрацияләр ясавы бик читен. Бу нисбәттән Тукай аерылып тора. Аның һәр әсәрендәге образларны, вакыйгаларны тасвирлау җиңел. Иң мөһиме — аның бөтен иҗаты халыкчан, татар тормышыннан алынган. Аның кайсы гына әсәрен кайта-кайта кабат алып укыма, үзең өчен яңалык табасың, яңа хисләр, яңа тойгылар, үйфикерләр белән баейсың. Тукай халкыбыз белән бер уй, бер өмет, бер хыялда яшәгән, иҗат иткән, шуңа да иҗаты мәңгелек!

*Февраль, 1986*

Көфер почмагы. 1985. Кәгазь, акварель, гуашь. 90×61
Угол неверных. 1985. Бумага, акварель, гуашь. 90×61

